**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге Тауасты Байлар торак пунктында
2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**27 ноябрь 2023ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Тауасты Байлар торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Тауасты Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- Тауасты Байлар торак пунктында Яшел урам буйлап вак таш сатып алу һәм салу (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү);
- Тауасты Байлар торак пунктында кышкы чорда юлларны грейдирлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Тауасты Байлар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menselinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы: ______________________ З. С.Гәрәева
(имза)